**Республика Татарстан**
**Глава Верхне-Чершилинского сельского поселения Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.03.2024 № 4

Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 №2, «Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнарның 2024 елда үзара салым кертү турында» 17.11.2023 №1 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1. 2024 елның 29 мартында 11.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Түбән Чыршылы авылының Горький урамындагы 9-нчы номерлы йорт янында "Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 №1, «Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында»17.11.2023 №2 гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 №1, «Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертүе турында» 17.11.2023 №2 гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы?

1) Түбән Чыршылы торак пунктында традицион җирләү урыннарын төзекләндерү ремонтлау, коймалар тоту (зират өчен хуҗалык бинасы урнаштыру, төзү материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

2) Түбән Чыршылы торак пункты территориясен төзекләндерү (махсус техникага хезмәт күрсәтү МТЗ - 82.1 тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

3) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Түбән Чыршылы торак пунктында кышкы вакытта юлларны кардан чистарту);

4) янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын ремонтлау (Түбән Чыршылы торак пунктында янгын сүндерү сулыкларын төзү, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

«ӘЙЕ «ЮК»

3.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында http:// sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Камалетдинов